**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы № 149 «21» июль 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2023 елның 30 октябрендәге 95 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (11.04.2024 №109, 07.10.2024 №122 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2025 елның 24 июнендәге №158-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Илбәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2023 елның 30 октябрендәге 95 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә (11.04.2024 №109, 07.10.2024 №122 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 3 өлешендәге 9 пунктында «составын һәм срокларын» сүзләрен «формалаштыру тәртибен, составын һәм срокларын һәм» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 43 статьяның 2 пунктында:

- беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм

структурасы нигезендә бюджет чыгымнарының һәр максатчан статьясы буенча бюджет турындагы карар белән раслана.»;

- өченче абзацта «1 апрельдә» сүзләрен «1 февральдә» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 46 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бюджет турында карар проектына бюджет ассигнованиеләрен муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре буенча бүлү турындагы карар белән расланган очракта, бюджет турында карар проектына муниципаль программаларның паспорты (паспорт проектлары) (күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары) тапшырыла.»;

1.4. 51 статьяның 1 пунктында «составы һәм сроклары» сүзләрен «формалаштыру тәртибе, составы һәм сроклары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның 1.2 пунктының дүртенче абзацы 2027 елның 1 гыйнварыннан кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай районы Илбәк авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.К.Галимҗанова